Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Күл-Черкен төп гомуми белем мәктәбе»

| **«Каралды»** | **«Килешенде»** | **«Раслыйм»** |
|---|---|---|
| Метод берләшмә җитәкчесе: | Уку-укыту эшләре буенча | Директор |
| _____Ф.Х.Әхмәтҗанова | директор урынбасары: | _______Р.Р.Хасанов |
| Беркетмә № 1 | _____Л.Р. Гибадуллина | Боерык № 57 |
| «24” август, 2020 нче ел | «24» август, 2020 нче ел | «24» август, 2020 нче ел |

5-9 нчы сыйныфлар өчен әдәбияттан эш программасы
Төзеделәр: Гиниятуллина Илдия Рифкать кызы
Хаттапова Фәридә Сөләйман кызы
Реализацияләү вакыты: 5 ел

Мәктәпнең педагогик киңәшмә утырышында
каралды һәм расланды
Беркетмә № 1
«24” август, 2020 нче ел

**Күл-Черкен авылы**

**2020 ел**

## УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Гомуми төп белем бирүче мәктәпләрдә татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда әдәби әсәрне аңлау-бәяләү күнекмәсе булдырыла, әхлакый позиция һәм эстетик зәвык тәрбияләнә, иҗади фикерләү үстерелә, һәм болар дөньяга карашны, тормышны бәяләү чарасына әверелергә тиеш.

Уртасыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми (метапредмет) нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;
- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

Уртасыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;
- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү,сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:

- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*эстетик яктан*:

- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

Бүгенге яшүсмер укучы алдагы буын укучылардан нык аерыла, телевидение, радио, интернет һ.б. бик күп мәгълүмат чаралары тирәлегендә үскән һәм тәрбияләнгән бала бай мәгълүматлы була, әмма еш кына әлеге мәгълүматлар аның рухи дөньясына тискәре йогынты да ясый. Шуңа күрә **шәхси нәтиҗәләр** арасында түбәндәгеләре аерым әһәмияткә ия:

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

Уртасыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предметара нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;
- татар теленә бәйләнештә, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү.

## ӘДӘБИЯТ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Урта сыйныфларда әдәбият укыту әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән укып танышу һәм аларны өйрәнү, тикшерү–анализлау һәм нәтиҗәләр ясауга, бәяләүгә йөз тота.  Укучыларда язучыларның тормышы, иҗаты турында (биографик), әдәбият тарихы, аның төрле этаплары, аерым чорлар әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләр, язучылар турында өстәмә, әдәби әсәрне, иҗатны тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик, әдәби әсәрне чор белән бәйләп характерлаучы,  чорның сыйфатларын, төп кыйммәтләрен табу өчен кирәкле мәгълүматларның туплануы мөһим.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятының аерым чорлары үзара бәйләнешле өйрәнелә башлый, аерым фольклор үрнәкләре, аларга анализ аша поэтик-фәлсәфи йөкләмәне, эчке, субъектив мәгънәне табу күнекмәләре формалаштырыла – болар әдәби иҗатка карата күзаллау булдыруда катнаша. Әдәби үрнәкләр белән танышу эше өч төрдә алып барыла: аерым әдәби әсәрләр уку һәм анализлау, аерым берләре укып фикер алышу, кайберләре сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителә. Әмма һәр очракта да алда куелган критерий һәм таләпләр истә тотыла.

### Әдәбият тарихы

***Әдәбият тарихын*** өйрәнү халык авыз иҗатыннан башлана.

**Халык авыз иҗаты**

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең үзенчәлекле сыйфатлары, аларда гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык авыз иҗатында образлар бирелеше. Фольклорда дөнья сурәте: каһарманлык, яхшылык һәм явызлык, яшәеш һәм кеше, кеше һәм табигать хакында күзаллаулар.

Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары. Әкиятләр, жанрлык сыйфатлары, жанр төрләре. Җыр жанрына хас сыйфатлар. Җырларны төркемләү. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүз. Кыска жанрлар: табышмаклар, мәзәкләр, мәкальләр һәм әйтемнәр. Бәетләр. Риваятьләр һәм легендалар, аларга хас үзенчәлекләр. Мифлар. Мифларның килеп чыгышы хакындагы карашлар. Мифларны төркемләү. Татар халык мифлары. Дастан жанрына хас сыйфатлар.

Халык авыз иҗаты поэтикасы (фантастик яки мифологик сюжет һәм детальләрдәге чынбарлыкка охшату; сурәтләү чаралары буларак кабатлау, каршылык, чиктән тыш арттыру, кечерәйтү, чагыштыру һ.б.). Татар халык авыз иҗатының башка халыклар фольклоры белән аваздашлыгы һәм аермалы яклары.

Әдәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнешләре. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе.

**Борынгы, урта гасырлар һәм XIX гасыр татар әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: гадел идарәче, мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б.Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек.

Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**XX йөз — XXI йөз башы татар әдәбияты**

XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

1920-1930 елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте.

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

**Әдәбият теориясе**

**Әдәби төр һәм жанрлар.** Эпос, лирика һәм драма төрләре. Жанр. «Жанр хәтере».Эпик жанрлар: роман, повесть, хикәя. Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Шәркый жанрлар системасы. Драма жанрлары: комедия, трагедия,

драма. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә.

**Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

**Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Лирик герой, хикәяләүче, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Табигать образы, әйбер образы, мифологик образ, фантастик образ, архетип.

**Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст.Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Текст: эпиграф, багышлау, көчле позиция.

**Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Лирик чигенешләр. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. Шигырь төзелеше. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж. Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

**Әдәбият тарихы.** Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият.

**Әдәби барыш.** Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты.

**Күнекмәләр формалаштыру**

Укучыга билгеле бер күләмдә белем бирү белән янәшә, аларны ныгыту, күнекмә дәрәҗәсендә беркетү кирәк була. Әдәбият шикелле белемнәр анализлау-тикшерү барышында үзләштерелә торган предмет өчен бу аерата мөһим. **Күнекмәләр булдыру** эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдә үстерелә һәм бәяләнә:

- **рецептив эшчәнлек**: әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләү; сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау.

- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, бәяли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.

- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьлеукый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; рольләргә кереп кабатлап бирү; план төзү һәм әсәрләр

турында бәяләмә язу, сочинение элементлары белән изложение язу; әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу.

- **эзләнү эшчәнлеге**: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирү.

- **тикшерену эшчәнлеге**: әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау; тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү;язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.

## Укыту курсының эчтәлеге

### 5 класс

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык иҗаты. Аның сәнгать төрләре формалашуга йогынтысы. Халык иҗатының бер төре буларак халык авыз иҗаты. Аның әсәрләрендә гомумкешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. Халык авыз иҗатының матур әдәбият белән бәйләнешләре: уртаклыгы һәм үзенчәлекле аермалары. Халык авыз иҗатының төп жанрлары, жанр сыйфатлары**.**

Әкиятләр: жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары. “Ак бүре” әкияте( кыскартып). “Үги кыз”, “Аю белән төлке” әкиятләре.

Җырлар: татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүзләр тәңгәллеге. “Моң” төшенчәсе. Җырларны төркемләү. “Иске кара урман”, ”Гөлҗамал”,”Туган ил”,”Яшә, Республикам!”,”Ай былбылым”; кыска җырлар - дүртюллыклар; тарихи җырлар: “Болгар иленең кызлары”,”Пугач явы”.

Кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр. табышмаклар, мәзәкләр. “Хуҗа Насретдин мәзәкләре”. Бәетләр. “Сак-сок” бәете.

Риваятьләр, легендалар: аларга хас үзенчәлекләр; жанр сыйфатлары.“Янмый торган кыз”,”Иске Казан каласының корылуы”,”Шәһәр нигә Казан дип аталган”,”Әллүки”,”Зөһрә кыз”,”Кеше гомере ничек корылган”.

Халык авыз иҗатында образлар; әсәрләрдә дөнья сурәте; табигать һәм кеше, яшәеш һәм кеше турында күзаллаулар. Халык авыз иҗаты поэтикасы, язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынтысы.

Әдәби әкиятләр: халык әкиятләре белән уртаклык; сәнгатьлелек сыйфатлары, әдәби әсәр буларак алым һәм сурәтләү чаралары.

Г.Тукайның “Шүрәле” әкияте.

Җ.Тәрҗемановның “Тукран малае Шуктуган” әкияте.

Әхмәт Фәйзинең “Аучы мәргән белән Болан кыз” әкияте.

Рабит Батулланың “Курай уйный бер малай” әкияте.

Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена”,”Кояштагы тап”әкиятләре.

Хикәя: жанр сыйфатлары; әсәрнең катламнары - вакыйгалар, күренешләр, хис- кичерешләр; кеше образлары - төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар; хикәяләүче образы, автор позициясе.Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһр әкыз”,”Нәҗип” хикәяләре.

Мәсәл. Тереклек, җансыз предмет образларыярдәмендә, читләтеп, кеше сыйфатларын һәм

тормышын тасвирлау. Хикәяләп яки тезмә рәвештә язылуы; фикер-идеяләрнең аллегория ярдәмендә белдерелүе.

Мәҗит Гафуриның “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле.

ГабдуллаТукайның “Ике сабан” мәсәле.

Сәнгать төре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм тезмә әсәр; аларның сәнгатьчә сурәтләү алымнары, чаралары.

Шигърият.

Габдулла Тукайның “Пар ат”,”Туган җиремә”,”Туган авыл” шигырьләре.

Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. “Һәркем әйтә дөресен”,”Тереклек суы”,”Курыкма, тимим!”, “Тарихтан сабак”,”Өйгә бирелгән эш” ,”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре

**6 класс**

**Мифлар. Дөньяны үзләштерүнең беренче баскычы буларак мифология**. Мифларда борынгы чор халыкларының табигать законнарын аңларга - күзалларга омтылулары. Дөнья халыклары иҗат иткән һәм татар халык мифлары арасында уртаклык - аерымлыклар.

Мисаллар нигезендә укытучы оештырган әңгәмә.

”Алып кешеләр”, ”Җил иясе җил чыгара”мифларында чынбарлыкны хыял ярдәмендә аңлатырга омтылу.

**Әдәби төрләр, жанрлар.Эпик төрнең жанрлары. Практик дәрес. Тема:** Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Образлар системасы. Әдәби алымнар, тел-сурәтләү чаралары. Матур әдәбият һәм башка сәнгать төрләре арасында образ иҗат итү үзенчәлеге.

**Әдәби әсәр. К.Насыйриның** тормышы, иҗаты, мәгърифәтче эшчәнлеге белән таныштыру.**Әбүгалисина”әсәрен** уку, анализлау.

**Г.Ибраһимовның** тормышы һәм иҗаты белән таныштыру.

**“Алмачуар” хикәясен** укып өйрәнү. Хикәяләү үзенчәлеген: эпиклык (чор, урын, кешеләр язмышы) белән лириклыкның (Закирның бик көчле теләге, хылы, эчке хис-кичерешләре, табигать күренешләре, Алмачуар образы) үзара аерылгысыз үрелеп тасвирлануда икәнлегенә анализ ясап бару.**Гали Рәхимнең** иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү.**”Яз әкиятләре” хикәясе** мисалында күчерелмә мәгънә, аллегория, символлар турында сөйләшү. Образлардагы яшерелгән мәгънәне - контекстны ачыклау .

**Лирик төр, үзенчәлекләре. Дәрдмәнднең** тормышы, иҗаты һәм әдәбиятта үзенчәлекле урыны турында кыскача белешмә. Исеме, тәхәллүсе. Күңелендәге катлаулы, каршылыклы хис-кичерешләре. Махсус тел-сурәтләү чаралары: эпитет, метафора, чагыштыру.

**Шигъри образлар. С.Рәмиевнең** тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат; шигырьләрдәге төп фикер, хис-кичерешләр һәм аларның күтәренке хис-пафос белән яңгыравы. Ике шагыйрьнең әсәрләрен чагыштыру.

**Әдәби төр һәм жанрлар. Драма төренең үзенчәлекләре**. Барлык сәнгать төрләрен дә берләштергән театр сәнгатенең нигезен тәшкил итүе. Театр һәм драматургия бердәмлеге. **Г.Камалның** театр, драматургия тарихында урыны роле

**”Беренче театр”да** көлүне тудырган сәбәпләр: махсус уйлап табылган ситуация, характерлы персонажлар, диалоглар. Әсәргә анализ: конфликтлар, сюжет хәрәкәте, төп геройлар, ярдәмче персонажлар.

**Г.Тукай иҗаты. Г.Тукайның** тормышы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны турында белгәннәрне искә төшерү. Күрсәтмә материаллар ярдә-мендә әстәмә белем бирү

Татар әдәбиятында беренче автобиографик әсәр булган **“Исемдә калганнар”ның** язылу тарихы. Балачак кичерешләрен тудырган сәбәпләр. Хикәяләү үзенчәлеге, хикәяләүче образы.

**Р.Батулланың «Имче», “Көчек”, ”Чагыр”** хикәяләре**.** Тукайның балачагы турында автор уйланмалары, күзаллавы.

**Лирик жанрлар Лирик герой. Практик дәрес. Тема:** Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы; табигать образлары. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре.

**Һ.Такташның“Урман”,“Пи-би-бип”,”Болай гади җыр гына”** шигырьләрендә лирик герой, образлар системасы, сурәтләү чаралары.

**Әдәби иҗат. Сәнгать алымнары. И.Газиның «Кояш артыннан киткән тургай”** хикәясе. Сурәтләү обьекты, **хи**кәяләүче образы, сурәтләү алымнары

**Ф.Яруллинның “Ак төнбоек”** хикәясе**.** Вакыйга, геройлар. Конфликт һәм сюжет этаплары. Хикәяләү алымнары.

**Балалар әдәбияты. Р.Миңнуллин** иҗаты, әдәбияттагы урыны, дәрәҗәле исемнәре турында мәгълүмат. **”Энекәш кирәк миңа!”, “Әни, мин көчек күрдем”, “Шундый минем туган ягым”, “Кайтыйк ла үзебезгә!”** шигырьләрендә образлар байлыгы, геройлар төрлелеге. Балачакны гәүдәләндергән образлар; әсәр геройлары һәм лирик герой образы, аларның хис-кичерешләре. Сурәтләү чаралары.

**Баллада жанры.** Балладаның үзенчәлекләрен: конкрет вакыйганы, геройларны сурәтләве - эпик төр сыйфаты; гадәттән тыш, тылсымга якын хәлләр, көчле соклану, горурлану хисләре;капма - каршы кую алымы, символик образлар, арттыру- көчәйтү алымнары - лирик төргә хас сыйфатларны һәр әсәрдә табып күрсәтә бару.**М.Җәлил “Сандугач һәм чишмә.”**

И.Юзеев ”Бакчачытурында баллада”,”Йолдыз кашка турында баллада”

**Эпик төр жанры . Роман** Хикәя һәм повесть жанрлары белән чагыштырып, романның сыйфатлары, уртаклык һәм аермалары турында сөйләшү. Өйрәнгән әсәрләр мисалында эпик төргә йомгак ясау.

**Ә.Фәйзи** иҗаты турында белешмә бирү.**”Тукай”** романының язылу тарихы. Әсәрне укып анализлау. “Исемдә калганнар” белән чагыштырып, Ә.Фәйзинең үз Тукаен иҗат иткәнлеге, автор нияте, фантазиясе турында сөйләшү.

## 7 класс

- **Төрләр һәм жанрлар. Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Әдәби алымнар (кеше образы тудыруга караган алымнар). Әдәби төр, жанр, эчтәлек һәм форма, әдәби алымнар турында белемнәр системага салына, тирәнәйтелә.**
- **Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. (кереш дәрес формасында
- **Халык авыз иҗаты.** Дастан жанрына хас сыйфатлар, аның төркемчәләре. Тарихи дастан буларак «Идегәй» дастаны (өзекләр)
- **XX гасыр башында сүз сәнгате**нең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

**Г.Тукайтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.«Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре.** Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре

- **Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү..«Яшь ана» хикәясе.**Әсәрдә хикәя жанры үзенчәлекләренең чагылышы.Әдәби әсәрдәге образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар.

- **Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.«Акчарлаклар» повесте (өзекләр).** Әсәрдә жанр үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт образы (хронотоп).
- **Чор: 1920-1930 еллар әдәбияты.** Әдәби барышка тәэсир иткән тарихи сәбәпләр. Аларның әдәбиятны каршылыклы үсешкә китерүе. Әдәби әсәрләр төрлелек: милли традицияләрне дәвам иттерүче һәм яңа идеология кысаларында иҗат ителгән әсәрләр
- **Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. "Мокамай" поэмасы. Лиро-эпик жанр - поэма.** Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт.Текст: эпиграф, багышлау.
- **Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.«Җан Баевич» комедиясе.** Драма төренең комедия жанры турында белгәннәрне тулыландыру. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).
- **Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү"Кызыл чәчәкләр" повесте.**Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.
- **Чор әдәбияты. XX гасырның икенче яртысында** татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы, аның тарихи сәбәпләре.Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүлә**р**
- **С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре.** Лирик жанр - күңел лирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре.
- **Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.**Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе.
- **Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Әни килде» драмасы.** Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).
- **Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Тәүге соклану», "Ярсулы яз" хикәяләре.** Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. **М.Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Без кырык беренче ел балалары» повесте.** Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).
- **М.Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү. "Уйна әле" хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.
- **Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Язмышның туган көне» хикәясе.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары.
- **З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү. «Сәер кыз» драмасы.** Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль.

- **Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр.
- **Р. Фәйзуллинның тормыш юлына кыскача күзәтү. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь” әсәрләре**, лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү.
- **Кабатлау һәм йомгаклау.**

**8 класс**

**Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.
**Урта гасырлар әдәбияты. Казан ханлыгы чоры**
Казан ханлыгы чорына кыскача тарихи, мәдәни, әдәби күзәтү.
**Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында мәгълүмат. «Нәсыйхәт» шигыре**. Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б. Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек. Символик образлар.
**XIX гасыр әдәбияты**
Чорга кыскача тарихи күзәтү. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. **Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» повесте**. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Әдәбиятта яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Повесть жанры. Әсәрнең сюжеты, тема, проблема, идеясе. Мәгърифәтчелек әдәбиятында төп тема - аң-белем, әхлак, тәрбия, һөнәрле булу, төп каршылык – искелек һәм яңалык көрәше. Мәгърифәтле шәхеснең сурәтләнеше: укымышлы, һөнәрле булу, дини кануннарны, Коръәнне яхшы белү. Хатын-кыз азатлыгының алгы планга куелуы.
**Сөйләм үстерү. Төп образларга характеристика язу.**
**XX гасыр башы әдәбияты**
Чорга кыскача тарихи күзәтү. XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.
(1 сәгать)
**М.Гафуриның «Нәсыйхәт» шигыре.** Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Әдәбиятта үгет-нәсыйхәт бирү. М.Гафуриның башлангыч чор иҗатында дидиктика - үгет-нәсыйхәт бирүнең өстенлек алуы. Үгет-нәсыйхәт бирүнең төп мотивы – кешене әхлаклы, аң-белемле итү. Лирик герой ихлас, гадел, ярдәмчел булырга, дөнья малына, аның ләззәтләренә кызыкмаска чакыра. М.Гафури иҗатында Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән традицияләрнең дәвам ителүе. Ритм, рифма, строфа үзенчәлекләре.
**Габдулла Тукайның «Дустларга бер сүз», «Мәхәббәт», «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырьләре**. Тормыш юлын, иҗатын искә төшерү, өстәмә мәгълүмат бирү. Шагыйрь иҗатының чорларга бүленеше, һәр чорга хас сыйфатлар. Лирик төр, лирик жанр үзенчәлекләре. Лирик герой образы. Шагыйрь иҗатында күтәрелгән төп мотивлар: уку-гыйлем –татар халкының наданлыгы, артталыгы өчен борчылу, бу хәлдән чыгу юллары турында уйлану; мәхәббәт – эчкерсез саф мәхәббәткә, аның кодрәтенә, хатын-кыз гүзәллегенә дан җырлау; шагыйрь – шагыйрьлек эше милли азатлык өчен көрәш идеясе белән үрелү. Тел-сурәтләү чаралары. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.Гражданлык лирикасы
**Шәриф Камалның «Буранда» хикәясе**. Язучының тормыш юлын искә төшерү. «Буранда» хикәясендә авторның төп максаты – Мостафаның кичерешләрен аңлату. Ананың хәсрәтле тормышы, төп геройның үкенү сәбәпләре икесенә карата да кызгану хисләре уята. Буран образы – адаштыра торган табигать күренеше генә түгел, Мостафаның әнисенә булган мөнәсәбәтендә зур ялгышуы, адашуы, хәзерге хисләре, күңел халәте. Әсәрнең фаҗигале тәмамлануы, аеручa үкенеч белән тасвирлануы хикәяне онытылмаслык итеп истә калдыра. Әдәби төр, жанрын билгеләү.

Образлар системасы: кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту.Троплар. Әсәрнең пафосы – сентименталь пафос. Язучы стиле. Әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль.

**Фатих Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясе**. Язучының тормыш юлын искә төшерү. Хикәядә авыр, кайгылы хәлләрнең сурәтләнүе. Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхетнең вакытлы булуы аша тормышның мәгънәсе юклыкка төшенү. Әсәрнең эчке катламын музыка аша бирү: Сөләйман карт елавы, капка, кыңгырау, бакча, сандугач тавышы, гитараның моңлы уйнавы, карчыкның йөткерүе карга каңгылдавы. Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасы: кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту.Троплар. Әсәрнең пафосы (сентименталь пафос), фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Язучы стиле: хикәя тормыш –яшәешкә ләгънәт укый, экзистенциализм фәлсәфәсен белдерә.

**Сөйләм үстерү. Фатих Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясенә бәя**

**Фәтхи Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе**. Язучының тормыш юлы белән танышу. «Таһир-Зөһрә» трагедиясен уку. Драма төренә анализ ясау үзенчәлекләрен искә төшерү. Конфликтын билгеләү. Шигырь белән язылган, дастан сюжетына нигезләнгән булуы, дөнья әдәбиятында киң таралган мәхәббәт һәм мәкер, гаделлек һәм явызлык көрәше. Трагедиянең пафосын (трагик пафос), язучы стилен билгеләү – әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль.

**20 – 30 нчы еллар әдәбияты**

30 нчы еллар әдәбиятында көрәш романтикасын сурәтләү. Тормышны матурлап, шартлылык кануннарына буйсындырып тасвирлау. Заманга хас яңа герой эзләү. **Әдәби барыш:** чор әдәбияты. **Һади Такташның «Алсу» поэмасы.** Үз чорының кичерешләрен, каршылыкларын чагылдырган иң популяр, танылган шагыйрь, прозаик, драматург буларак тормышы, иҗаты белән таныштыру. «Алсу» поэмасында яшьлекнең, көрәш романтикасының сурәтләнеше. **Әдәби төр һәм жанрлар.** Лиро-эпик жанр – поэма. **Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Характер. Лирик герой, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. **Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. **Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.

**Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте**. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Психологизм.

Мәхәббәт, гаилә кору темасын ачу. Конфликтның кемнәр арасында баруы, сәбәпләре, чишелеше ягыннан әсәрне анализлау. Төп конфликтның эчке конфликт булуына басым ясау. Галиянең хатларны үзе өчен язуын ачыклау. Сюжет этапларыначу. Эпистоляр повесть жанры.

Гадел Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повестенда Искәндәр һәм Вәли образлары”

«Тапшырылмаганхатлар» повестендамәхәббәт-гаиләпроблемасыныңхәлителеше.

Галиянең 4 хаты да Искәндәргә тапшырылган дип уйлап, Искәндәр исеменнән Галиягә хат языгыз. Галиягә яки Искәндәргә үзегез хат языгыз.

**Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы.** Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Фаҗигале драма жанрында язылган әсәрнең сюжет-композициясен ачыклау. Кеше бәхете темасының бирелеше, драманың проблема, идеясен билгеләү . Төп образларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешен өйрәнү. Портрет. Психологизм . Язучы стиле - фаҗигале.

**СөйләмүстерүСочинение**

Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында төп образларның бирелеше.

Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында күтәрелгән проблемалар.

«Сүнгән йолдызлар» драмасының сәнгатьчә эшләнеше.

**Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты**

**Фатих Кәримнең «Сибәли дә сибәли», «Ант», «Ватаным өчен», «Теләк», «Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Бездә яздыр», «Газиз әнкәй» шигырьләре.** Тормыш юлы турында мәгълүмат.

Иҗатының чорларга бүленеше. Сугыш чоры иҗатының үзенчәлекләре: җиңүгә ышаныч белән илен сакларга ант итү; лирик геройның рухи дөньясы баю; яшәү һәм үлү турында фәлсәфи уйлануы; фашизмга нәфрәт хисләре; туган ягын, якыннарын сагыну. Гражданлык лирикасы, күңел лирикасы.Сугыш чорында шагыйрь иҗатының поэма һәм баллада жанрында иң югары ноктага җитүе. «**Кыңгыраулы яшел гармун**» поэмасында сугышчының күңел дөньясы, хис-кичерешләрен лирик планда сурәтләү. **«Сибәли дә сибәли»** шигырендә сугыш фаҗигасен табигать күренешләре, тел-сурәтләү чарасы сынландыру, әдәби алым кабатлау аша тасвирлау.
**60-80 нче еллар әдәбияты.** XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы
**Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте**. (кыскартып). Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повестьта халык тормышының тулы бер панорамасы чагылу. Әсәрдә туган ил, халкың белән горурлану хисе тасвирлана, повесть укучыларда хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли. Сурәтләнгән геройларның, вакыйга-күренешләрнең тормышчан булуы, шулар аша әдип татар авылының үткәнен һәм бүгенгесен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, халыкның күңел байлыгын, гомумән, милли сыйфатларын тасвирлый. Г.Бәширов - портрет, табигатьбизәкләре, характер остасы; Гумәробразыныңбирелеше. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Язучы стиле.
**Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повесте**Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повесть жанры. Хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмияте. Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. Тел-стиль чаралары. Әсәр исеменең эчке һәм тышкы мәгънәгә ия булуы. Заманга тәнкыйди бәя. Язучы стиленең үзенчәлекләре.
**Сөйләм үстерү. Сочинение**.
“Кешеләргә изгелек кылып яшәү – үзе бәхет”.
Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда яшь кеше образларының бирелеше.
Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда образлар системасы.
Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда заманга тәнкыйди бәя чагылышы.
Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повестенда язучы стиленең үзенчәлекләре.
**Миргазиян Юныс “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повесте** Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повесть жанры. Хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмияте. Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. Тел-стиль чаралары. Әсәр исеменең эчке һәм тышкы мәгънәгә ия булуы. Заманга тәнкыйди бәя. Язучы стиленең үзенчәлекләре.
Сөйләм үстерү Әдәби әсәргә бәя
**Равил Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга…», «Аккошлар», «Мин сиңа йомшак таң җиле…»“Вакыт”, “Якты моң”, һәм кыска шигырьләре.**
Шагыйрьнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Иҗатка 60 нчыеллардакилүе, яңача ритмика, рифма, образларсистемасытудыруы. Р.Фәйзуллинкыскаформаларгамөрәҗәгатьитә, аларда метафора алгыплангачыга. Лирик әсәрләргә анализ ясауүзенчәлекләре. Табигыйхис-кичерешләрчагылыштапканшигырьләренеңҗырларбулыпкитүе. Фәлсәфи лирика. Сөйләмүстерү Сочинение
Равил Фәйзуллин – фәлсәфи-лирик шагыйрь.
Равил Фәйзуллинның мәхәббәт лирикасы.
“Кыска шигырь – оста шагыйрь” Равил Фәйзуллин иҗатында форма хасиятләре.
**Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе.** Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Каршылыкның төрләре: төп сюжет сызыгында тышкы каршылык Әлмәндәр һәм Әҗәл арасында, эчке каршылык Әҗәл күңелендә; ярдәмче сюжет сызыкларында тышкы каршылык Әлмәндәр белән Өммия, Әлмәндәр

белән Искәндәр арасында формалаша. Төп сюжет сызыгындагы эчке каршылыкның төп каршылык булуы. Әсәрнең фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Әлмәндәр образының бирелеше, аның замандаш сыйфатларын туплаган, халыкчан образ-характер булуы. Комедиянең тел-сурәтләү чараларына, кинаяле тезмәләргә байлыгы. Реаль тормыш картиналарының шартлылык һәм символлар белән тыгыз кушылып китүе, шуның белән әсәрдәге төп идеяне тулырак ачуга ирешү.
**Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте**. Әдипнең тормышы, иҗаты турында мәгълүмат бирү. «Җилкәннәрҗилдәсынала» повестеның–автобиографик повесть булуы. Кешенеданлау, зурлаутемасыныңбирелеше. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Язучы стиле.
**Мөдәррис Әгъләмовның «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре**. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру. Классик шигырьгә йөз тотып иҗат итүе. Кешене данлау, зурлау темасының бирелеше. Лирик әсәрләргә анализ ясау үзенчәлекләре. Лирик жанрлар: гражданлык лирикасы, күңел лирикасы. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Шигырь төзелеше. Язучы стиле: экзистенциаль башлангыч.
Йомгаклау дәресе

**Дәрестән тыш уку өчен әсәрләр**

1. Дәресләргә әзерләнгәндә, вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.
2. Мәдинә Мәликова “Чәчкә балы”
3. Фәүзия Бәйрәмова “Кыңгырау”
4. Татар әдәбиятында шагыйрәләр иҗаты: Л.Шагыйрьҗан, Э.Мөэминова, Н.Сафина, Р.Вәлиева, Б.Рәхимова, Э.Шәрифуллина, А.Минһаҗева. Шагыйрәләр иҗатын өйрәнеп, проектлар яклау дәресе.
5. Хәзерге татар әдәбиятында яшьләр иҗаты. Проектлар яклау дәресе

## 9 класс

**Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше, үсеш баскычлары. Әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма ягыннан тирәнрәк, тулырак бәяләү. Шигырь төзелешен өйрәнү, аның төрләрен аерып чыгару.**

**Сәнгать төре буларак әдәбият.** Сәнгать төрләре һәм әдәбият. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып белүгә хезмәт итүе. Әдәбиятның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

Сүз сәнгате. Эстетик идеал.

**Әдәбиятның барлыкка килүе һәм үсеше.** Гомумтөрки мәдәният һәм әдәбият. Ислам мәдәнияте. Мәдәни һәм әдәби күренеш буларак суфичылык. Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Торгынлык чоры мәдәнияте, әдәбияты (16 гасырның 2 нче яртысыннан 19 нчы гасырның 2 нче яртысына кадәр) турында мәгълүмат бирү. Әлеге чорлар әдәбиятында төп тема-мотивлар, романтик сурәтлелек, аның билгеләре. Әсәрләрнең Коръән тәгълиматы белән сугарылуы. Дөньяви мотивларның урыны.

Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше, үсеш баскычлары. Урта гасырлар романтизмы. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият. Әдәби жанрлар.

**XIX гасыр татар әдәбияты.** Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**З.Бигиевнең** «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы (өзекләр). Детективлыкка нигезләнгән сюжеты. Матди һәм рухи байлыкка бәйле туган конфликт. Төп образлар, аларның эш-гамәле. Аерым геройлар фаҗигасенең сәбәпләре.

Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты. Әдәбиятта традицияләр һәм яңачалык.

**XX гасыр башында** сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләре. Әдәбиятта яңа юнәлешләр һәм агымнар барлыкка килү. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

**Ф.Әмирханның** «Хәят» повесте. Хатын-кыз азатлыгы, шәхес иреге, мәхәббәт мәсьәләләренең үзәккә куелуы. Дин кануннарына нигезләнгән милли тормышның русча яшәү үрнәге белән каршылыкка керүе. Хәят образы, аның рухи кичерешләрен ачуда әдипнең осталыгы, алым-чаралар муллыгы. Портрет һәм пейзажның әдәби-эстетик функциясе.

Эпик төр. Повесть. Образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Пейзаж, портрет. Психологизм.

**Г.Камалның** «Банкрот» комедиясе. Ялган банкротлыкка чыгу вакыйгасының реаль җирлеге. Комедиячел конфликт. Сиражетдин образы. Әсәрдә көлү алымнары. Шул чор татар җәмгыятендәге кимчелекле якларның усал тәнкыйтьләнүе. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең заманчалыгы. Г.Камал әсәренең Н.А.Островскийның "Үз кешеләр – килешербез" комедиясе белән охшашлыгы.

Драматургия жанрлары. Комедия. Автор идеалы. Язучы стиле.

**1917 – 1940 еллар әдәбияты.** Әлеге дәвердә татар әдәбиятының берничә этап аша үтүе. Чорга кыскача күзәтү. Иҗтимагый-тарихи, социаль-мәдәни шартлар. Әдәбиятта сыйфат үзгәреше, аңа идеология тәэсире. Әдәбиятта тарихи-иҗтимагый вакыйгаларның сурәтләнеше.

**М.Галәүнең** «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр). Романда 19 йөз ахыры татар тормышы сурәтләнү. Ил-халык тормышының бер гаилә эчендәге каршылыклар рәвешендә сурәтләнүе. Әсәрдә татарларның яшәү рәвеше, сыйфат-билгеләре чагылыш табу. Төрле социаль катлаулар тормышы. Халыкның властька, дин әһелләренә мөнәсәбәте. Әсәрдәге төп образлар, аларның характер сыйфатлары. Татар җәмгыятендә хатын-кызның урыны, роле. Саҗидә образы.

Эпик төрнең бер жанры буларак роман. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп).

**Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты.** Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Лирика һәм публицистиканың алга чыгуы. Кече жанрларның активлашуы. Төп тема-мотивлар, проблемалар. Сугыш чынбарлыгы һәм аны сурәтләү үзенчәлекләре

**Г.Кутуйның** «Сагыну» нәсере. Лирик герой кичерешләренең чагылу үзенчәлеге. Сурәт чараларының әдәби функциясе.

Символ, деталь. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

**Муса Җәлилнең** «Моабит дәфтәрләре»ннән: «Җырларым», «Кошчык», «Тик булса иде ирек», «Ышанма», «Катыйльгә», «Бер үгет» шигырьләре.

Тормыш юлы, батырлыгы һәм иҗаты. Шагыйрь иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлык чоры иҗатының үзенчәлекләре: коллыктан котылу чарасы буларак үлем, аның үлемсезлеккә илтүе; Ватанга бирелгәнлекне, тугрылыкны раслау; дошманга нәфрәтнең чагылышы һ.б. Шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеше: кабатлау, эпитет, метафора, антитеза, риторик эндәшләрнең хис дәрәҗәсен арттыруга хезмәт итүе. Традицион символик образларның яңа төсмерләргә баюы.

Шагыйрь иҗатын, көрәшен чагылдырган әдәби һәм фәнни хезмәтләр.

**Ә.Еникинең** «Кем җырлады?» хикәясендә сугыш фаҗигасе чагылышы. Яралы лейтенантның яшәү-үлем халәтендәге кичерешләренең туган як, туган җир, ата-ана, сөйгән кеше якынлыгын калкытып куюы, аларның яшәеш мәгънәсе булуын ачуы. "Бала" хикәясендә яшь солдат Зарифның күңел кичерешләре, рухи батырлыгы сурәтләнү. "Ана белән кыз" хикәясендә

сугыш шартларында яшәгән кешеләрнең күңел халәтен, сабырлык-түземлеген, өмет хисен әдәби детальләр, сурәт чаралары аша укучыга җиткерү .

Әсәрнең эчтәлек һәм формасы. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш.

**Сугыштан соңгы һәм 1960-80 нче еллар әдәбияты.** XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Әлеге чорда яңа жанрлар, тема-мотивлар, әдәби формалар барлыкка килү. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

**Х.Туфанның** «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» шигырьләре. Иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлык чоры иҗатына караган шигырьләрендә кешегә хас хис-кичерешләрнең төрлелеге. Сагыш, сагыну, тормыш гаделсезлегенә ачынуның алгы планга чыгуы. Лирик герой күңелендәге өмет-ышанычның киләчәк матурлыгы булып ачылуы. Сурәт чаралары муллыгы.

Лирик жанрлар:  күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Лирик герой,  лирик “мин”, автор образы, автор позициясе.  Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.

**И.Юзеевнең** “Сагышлы мирас”, “Гасыр кичкән чакта”, “Без”, “Калдыр, аккош, каурыеңны” шигырьләре. Шагыйрьнең романтик шигърият вәкиле булып танылуы. Лирик героеның төрле төсмерләрдә чагылыш табуы: яшьлеген, аның серле таңнарын сагынучы; ашкын хисле, көчле рухлы шәхес; мәхәббәт утында янучы гашыйк һ.б. Әдипнең туган җир, тел, ата-ана, әхлакый кыйммәтләр сакланышы, Җир, Галәм язмышы кебек мәсьәләләргә актив мөрәҗәгать итүе.  “Өчәү чыктык ерак юлга” поэмасында чор-заман мәсьәләләрнең өч герой язмышы аша сурәтләнеше. Символик образларның, әдәби детальләрнең автор идеясен ачудагы роле.

Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар)

**А.Гыйләҗевның** «Җомга көн, кич белән» повесте. Әдипнең кырыс реализмга нигезләнеп язуы. Әсәрдә әхлак тәрбиясе, ата-ана каршындагы бурыч,  намус җаваплылыгы кебек төшенчәләрнең гыйбрәтле вакыйга-күренешләрдә чагылышы. Бибинур карчык образы: изгелеге, көчле рухы, милли характер булып ачылуы. Корбанчылык идеясенең чагылышы. Әсәрдә символик образларның, әдәби детальләрнең роле. Әсәр исеменә салынган тирән мәгънә.

Тема, проблема, идея, пафос. Текст: эпиграф, башлам (пролог), бетем (эпилог). Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.

**Н. Фәттахның** «Ител суы ака торур» романы (өзекләр). Әсәрдә борынгы бабаларыбыз – болгарлар тормышының, гореф-гадәтләренең мавыктыргыч, гыйбрәтле вакыйгаларда сурәтләнеше. Романда тарихи дөреслек һәм автор уйланмасы. Төп образлары, аларның  эш-гамәлендә ачылган характер сыйфатлары. Ител образы.

Персонаж, характер, тип.  “Эзоп теле”.

**Т.Миңнуллинның** «Кулъяулык» музыкаль драмасы.Әсәрнең сюжет-композициясе, конфликт үзенчәлеге. Татар милләтенә хас булган гореф-гадәтләрләрнең онытыла баруына борчылу идеясе. “Бәхет”төшенчәсен аңлау-аңлату. Кулъяулык образына, җырга салынган мәгънә. Автор позициясе.

Музыкаль драма. Автор образы, автор позициясе.

**Хәзерге әдәбият.** XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләре, эзләнүләрнең “яңа дулкын” булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгын чагылдырган, ил тарихындагы олы этапларның, аерым шәхесләрнең  сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

**Дөнья әдәбиятының барышы.** Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар. (1 сәгать)

**З.Хәкимнең** “Телсез күке” драмасында ретроспектив алым ярдәмендә халык тормышының киң понарамасын чагылдыру. Милләт язмышының вакыйгаларны иңләп үтүе. Ата-баба телен белү, җыр-моңын өйрәнүнең чикләрне белми торган изге төшенчә буларак ачылуы. Шәхес һәм система каршылыгына нигезләнгән конфликт, аның чишелеше. Зариф һәм Зыятдин образлары. Татар җыр-моңының символик образ буларак туган җир матурлыгын, халыкның фаҗигале язмышын, теләк-өметен чагылдыруы.

Драма жанры һәм жанр формалары.

**Ф.Садриевның** «Таң җиле» романы (өзекләр). Кырыс чынбарлыкның романтик алымнар аша сурәтләнүе. Көнкүреш вакыйгасының илкүләм әһәмиятле иҗтимагый, социаль-мәдәни, әхлакый мәсьәләләргә барып тоташуы. Романда совет җәмгыятенең кискен тәнкыйтьләнүе. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы. Нуриасма образы: милли йөзе, характер сыйфатлары, яшәеш идеалы. Намусларына хыянәт иткән типлар.

Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.

**Зөлфәтнең** «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре. Шагыйрьнең классик традицияләренә йөз тотуы. Шигырьләренең халык язмышына бәйле публицистик яңгырашы. Заман сорауларын Кеше шәхесе, аның хис-кичерешләре аша чагылдыручы фәлсәфи-лирик шагыйрь булып танылуы. Иҗатында чичәнлек рухы.

Шигырь системалары турында мәгълүмат.

## Тематик планлаштыру

### 5 класс

| № | Төптемалар | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш. Халыкавызиҗаты | 1 |
| 2 | Әкият. "Ак бүре" әкияте | 4 |
| 3 | "Үгикыз", "Аюбеләнтөлке" әкиятләре | 3 |
| 4 | Халык авыз иҗатында җыр жанры. "Иске кара урман", "Гөлҗамал", "Туган ил", "Яшә, Республикам!", "Ай былбылым"; кыска җырлар -дүртьюллыклар; тарихи җырлар: "Болгар иленең кызлары", "Пугач явы" | 4 |
| 5 | Халык авыз иҗатында кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр. "Хуҗа Насретдин мәзәкләре" | 5 |
| 6 | Бәетләр. "Сак-сок" бәете | 2 |
| 7 | Риваятьләр, легендалар. "Янмый торган кыз","Иске Казан каласының корылуы","Шәһәр нигә Казан дип аталган","Әллүки","Зөһрәкыз","Кеше гомере ничек корылган" | 4 |
| 8 | Практик дәрес.Халык авыз иҗатында образлар | 2 |
| 9 | Әдәбиәкиятләр. Г.Тукай "Шүрәле" | 2 |
| 10 | Җ.Тәрҗемановның "Тукран малае Шуктуган" әкияте | 4 |
| 11 | ӘхмәтФәйзинең "Аучы мәргән белән Боланкыз" әкияте | 3 |
| 12 | Рабит Батулланың "Курай уйный бер малай" әкияте | 3 |
| 13 | Фәнис Яруллинның "Зәңгәр күлдә ай коена", "Кояштагы тап" әкиятләре | 3 |
| 14 | Хикәя. ФатихӘмирханның "Ай өстендә Зөһрә кыз", "Нәҗип" хикәяләре | 5 |
| 15 | Мәсәл. Мәҗит Гафуриның "Сарыкны кем ашаган?" мәсәле | 2 |
| 16 | Габдулла Тукайның "Ике сабан" мәсәле | 1 |
| 17 | Практик дәрес. Сәнгать төре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | тезмә әсәр | |
| 18 | Габдулла Тукайның "Пар ат", "Туган җиремә", "Туган авыл" шигырьләре | 3 |
| 19 | Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлардөньясы. "Һәркем әйтә дөресен", "Тереклек суы", "Курыкма, тимим!", "Тарихтан сабак", "Өйгә бирелгән эш", "Онытылган, өйдә калган" шигырьләре | 3 |
| 20 | Ф.Яруллин "Сез иң гүзәл кеше икәнсез" | 1 |
| 21 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 7 |
| 22 | Дәрестән тыш уку | 3 |
| 23 | Йомгаклаудәресе | 1 |
| | Барлыгы: | 70 |

**6 класс**

| Тема, бүлекләр | Сәгать саны |
|---|---|
| Мифлар.<br>“Алып кешеләр”, “Җил иясе җил чыгара” | 5 |
| Әдәби төрләр, жанрлар К.Насыйриның “Әбүгалисина”әсәрен уку, анализлау. | 5 |
| Эпик төрнең жанрлары. Г.Ибраһимов “Алмачуар” хикәясе | 5 |
| Әдәби әсәр.<br>Гали Рәхимнең ”Яз әкиятләре” хикәясе | 3 |
| Эпик төрнең жанрлары Дәрдемәнд, С.Рәмиев | 4 |
| Әдәби әсәр.<br>Г.Камал “Беренче театр”, Г.Тукай “Исемдә калганнар”. | 4+5 |
| Лирик әсәрләр.<br>Һ.Такташ | 4 |
| Г.Тукай турында хикәяләр.<br>И.Гази “Кояш артыннан киткән тургай”, Р.Батулла “Имче”, “Көчек”, “Чагыр”, Ф.Яруллин “Ак төнбоек” | 10 |
| Балалар әдәбияты. Р.Миңнуллин, М. Җәлил | 8 |
| Балладалар | 5 |
| Зур күләмле әсәрләр: роман.<br>Ә.Фәйзинең “Тукай” романыннан өзекләр | 5 |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү, дәрестән тыш уку | 7 |

**7 класс**

| № | Тема, бүлекләр | Саны |
|---|---|---|
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият. | 1 |
| 2-4 | Халык авыз иҗаты. «Идегәй» дастаны | 3 |
| 5 | XX гасыр башы әдәбияты. | **1** |
| 6-8 | Г.Тукай. «Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре. | 3 |
| 9-10 | БСҮ “Минем милләтем – минем горурлыгым” | 2 |
| 11-13 | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясе. | 3 |
| 14-16 | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повесте | 3 |
| 17 | 1920-1930 елларда әдәбияты. | **1** |
| 18-20 | Һ.Такташ. “Мокамай” поэмасы. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| 21-22 | БСҮ “Чын дустым” | 2 |
| 23-26 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе. | 4 |
| 27 | ДТУ Г.Исхакый “Кәҗүл читек” | 1 |
| 28-31 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повесте. | 4 |
| 32 | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. | 1 |
| 33-34 | С.Хәким. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. | 2 |
| 35 | ДТУ С.Хәким. “дәверләр капкасы” | 1 |
| 36-39 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе. | 4 |
| 40-43 | Ш.Хөсәенов. «Әни килде» драмасы. | 4 |
| 44-45 | БСҮ “Әнием – бәгырем” | 2 |
| 46-48 | Г. Сабитов. «Тәүге соклану», “Ярсылу яз” хикәяләре. | 3 |
| 49-52 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повесте. | 4 |
| 53-54 | М.Галиев. “Уйна әле” хикәясе. | 2 |
| 55-56 | БСҮ. “Шинельле һәм шинельсез солдатлар” | 2 |
| 57 | ДТУ | 1 |
| 58-60 | Г.Гыйльманов. «Язмышның туган көне» хикәясе. | 3 |
| 61-63 | З.Хәким. «Сәер кыз» драмасы. | 3 |
| 64-66 | Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы. | **3** |
| 67 | ДТУ | 1 |
| 68-70 | Р. Фәйзуллин. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь” әсәрләре. | 3 |

**8 класс**

| № | **Бүлек һәм темаларның исеме** | саны |
|---|---|---|
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият | 1 |
| 2 | Уртагасырларәдәбияты. Казан ханлыгычоры | 3 |
| | XIX гасыр әдәбияты<br>Чорга кыскача тарихи күзәтү | 4 |
| 3 | XX гасырбашыәдәбияты<br>Чоргакыскачатарихикүзәтү | 16 |
| 4 | 20 – 30 нчыелларәдәбияты | 15 |
| 5 | БөекВатансугышычорыәдәбияты | 3 |
| 6 | 60-80 нчеелларәдәбияты. ГомәрБәшировның «Туганягым – яшелбишек» автобиографикповесте | 4 |
| 7 | АязГыйләҗевнең “Язгыкәрваннар” повесте | 6 |
| 8 | МиргазиянЮныс “Биектәкалу” (“Шәмдәлләрдәгенәутларяна”) повесте | 4 |
| 9 | РавилФәйзуллинның «Җаныңныңваклыгынсылтамазаманга…», «Аккошлар» һ.б. шигырьләре | 2 |
| 10 | ТуфанМиңнуллинның «ӘлдермештәнӘлмәндәр» моңсукомедиясе | 4 |
| 11 | Фәнис Яруллинның «Җилкәннәрҗилдәсынала» повесте | 3 |
| 12 | Мөдәррис Әгъләмовның «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре | 2 |
| 13 | Йомгаклаудәресе<br>Резерв дәрес | 2<br>1 |

**9 класс**

| № | Төп бүлекләр, темалар | саны |
|---|---|---|
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият Тарихи-әдәби процесс | 2 |
| 2 | Гомумтөрки әдәбият **М.Кашгарый,Й.Баласагунлы** “Котадгу белек “әсәре | 2 |
| 3 | Казан ханлыгы чоры әдәбияты **Мөхәммәдъяр** “ Төхфәи Мәрдан”, “Нуры Содур | 2 |
| 4 | Торгынлык чоры әдәбияты**Мәүла Колый, Г.Утыз Имәни** | 1 |
| 5 | Яңа заман татар әдәбияты. XIXгасыр татар әдәбияты М. Акъегетзадә ”Хисаметдин менла”, З.Бигиев “Зур гөнаһлар”, Ф.Кәрими ”Морза кызы Фатыйма” Һ.Б.әсәрләре | 2 |
| 6 | XX гасыр башында татар әдәбияты **Ф.Әмирхан** тормышы һәм иҗаты “Хәят. **Г.Камал** “Банкрот ”сатирик комедиясе | 9 |
| 7 | 1917- 1941 еллар әдәбияты **Мәхмүт Галәү** тормышы һәм иҗаты. “Мөһаҗирләр” романы | 5 |
| 8 | Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты **Гадел Кутуй** тормышы һәм иҗаты. “Сагыну ”нәсере, **Муса Җәлил** тормышы һәм иҗаты, **Ә.Еники иҗаты** | 12 |
| 9 | Сугыштан соңгы һәм 1960- 1980 еллар әдәбияты **Хәсән Туфан, И.Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Т.Миңнуллинның** иҗат дөньясы | 18 |
| 10 | Хәзерге татар әдәбияты **Зөлфәт Хәким, Фоат Садриев, Зөлфәт**тормышы һәм иҗаты | 13 |
| 11 | Гомумиләштереп кабатлау | 2 |